ГЛАВА РОДНИКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
РОДНИКИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2021 №9

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Родники авыл җирлегенең Тигән-Бүләк
авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Родники авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Родники авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Родники авыл җирлегенең Тигән-Бүләк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 16 декабреән 17 декабренә кадәр график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Родники авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Родники авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ   ЮК».

4. Әлеге карарны Родники авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Родники авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районын**
**Родники авыл җирлеге башлыгы** **Е.А. Яковлева**

Кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының**
**Родники авыл җирлегенең Тигән-Бүләк авылында**
**үзара салым кертү мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын этаплап уздыру**
**ГРАФИГЫ**

| **Тәртип саны** | **Үткәрү датасы** | **Үткәрү вакыты** | **Үткәрү урыны** | **Урамнарның исеме** |
|---|---|---|---|---|
| **1** | 16.01.2022 | 13.00 сәг. | Тигән-Бүләк, Киров ур., 1 й. АК | Киров ур., 5-17 й. |
| **2** | 16.01.2022 | 15.00 сәг. | Тигән-Бүләк, Киров ур., 1 й. АК | Киров ур., 18-28 й. |
| **3** | 17.01.2022 | 10.00 сәг. | Тигән-Бүләк, Киров ур., 1 й. АК | Чапаев ур., 1-6 й. |
| **4** | 17.01.2022 | 12.00 сәг. | Тигән-Бүләк, Киров ур., 1 й. АК | Чапаев ур., 7-28 й. |
| **5** | 17.01.2022 | 14.00 сәг. | Тигән-Бүләк, Киров ур., 1 й. АК | Чапаев ур., 29-41 й. |